ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
27.12.2024

г.Казань

**КАРАР**
№ 738-265/тп-2024

«Су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су агызуның үзәкләштерелгән системаларына тоташтыруга түләү» чараларын финанслау чыганагы булган инвестиция программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларның үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларына тоташтыруга (технологик ялгауга) түләү исәпләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләрен раслау хакында» 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карарлары һәм Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мөрәҗәгать итүчеләр объектларының үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызу системаларына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү индивидуаль тәртиптә билгеләнә торган тоташтырыла торган (ялгана торган) йөкләнеш күләмен билгеләү турында» 2017 елның 22 апрелендәге 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2024 елның 27 декабрендәге 38-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су агызуның үзәкләштерелгән системаларына тоташтыруга түләү» чараларын финанслау чыганагы булган инвестиция программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларның үзәкләштерелгән су

белән тәэмин итү һәм су агызу системаларына тоташтыруга (технологик ялгауга) түләү әлеге карар кушымтасы нигезендә исәпләнә дип билгеләргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В.Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.12.2024 № 738-265/тп-2024
карарына кушымта

«Су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су агызуның үзәкләштерелгән системаларына тоташтыруга түләү» чараларын финанслау чыганагы булган инвестиция программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларның үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларына тоташтыруга (технологик ялгауга) түләү исәплəү

1. Су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләүне исәпләү «су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су агызуның үзәкләштерелгән системаларына тоташтыруга түләү» чараларын финанслау чыганагы булган тоташтыруны (технологик ялгауны) гамәлгә ашыручы һәм инвестиция программасын гамәлгә ашыручы оешмага үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызу системасына тоташтыру (технологик ялгау) шартнамәсе төзү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән затларга, шул исәптән су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су агызуның үзәкләштерелгән системасына тоташтыруны (технологик ялгауны) планлаштыручы төзүчеләргә (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) карата кулланыла.

2. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызу системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү тоташтыруны (технологик ялгауны) гамәлгә ашыручы оешманың инвестиция программасын раслаганда тоташтырыла торган йөкләнешнең бәясен вәкаләтле республика башкарма хакимияте органы билгеле торган инвестиция өлешен үз эченә ала.

3. Объектларның тоташтырыла торган (ялгана торган) йөкләнеше күләме тәүлегенә 50 куб метрдан артмаган мөрәҗәгать итүчеләрне үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызу системасына тоташтырган (технологик ялгаган) өчен түләү түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ПП_{<50} = Т^{п,м} * М + \sum Т_d^{пр} * L_d + С_{ип} * М, \text{ (формула 1)}$$

биредә:

$ПП_{<50}$ - мөрәҗәгать итүче объектын үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызу системасына тоташтырган өчен түләү, мең сум;

$Т^{п,м}$ - суүткәргеч яисә канализация челтәренә тоташтырыла торган йөкләнеш өчен тариф ставкасы, тәүлегенә мең сум/куб.м.;

М – мөрәҗәгать итүче объектының тоташтырыла торган йөкләнеше (егәрлеге), куб.м/тәүлек;

$Т_d^{пр}$ - диаметры d булган суүткәргеч яисә канализация челтәре озынлыгы өчен тариф ставкасы, мең сум/км;

$L_d$ - мөрәҗәгать итүче объектын тоташтыру ноктасыннан оешма тарафыннан төзелә торган суүткәргеч һәм (яисә) канализация челтәрләренең үзәкләштерелгән су

белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызу системасы объектларына тоташтыру ноктасына кадәр суүткәргеч яисә канализация челтәренең озынлыгы, км;

$С_{ип}$ - билгеләнгән тәртиптә расланган инвестиция программасы нигезендә су белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызу өлкәсендәге чаралар буенча тоташтырыла торган йөкләнешнең бәясе, тәүлегенә мең сум/куб.м.

4. Объектларның тоташтырыла торган (ялгана торган) йөкләнеше күләме тәүлегенә 50 куб метрдан арткан мөрәҗәгать итүчеләрне үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызу системасына тоташтырган (технологик ялгаган) өчен түләү түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ПП_{>50} = ПП_{И} + С_{ип} * М, \text{(формула 2)}$$

биредә:

$ПП_{>50}$ - мөрәҗәгать итүче объектын үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасына тоташтырган өчен түләү, мең сум;

$ПП_{И}$ - тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимияте органы тарафыннан индивидуаль тәртиптә исәпләнгән тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү, мең сум;

М – мөрәҗәгать итүче объектының тоташтырыла торган йөкләнеше (егәрлеге), куб.м/тәүлек;

$С_{ип}$ - республика башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан расланган инвестиция программасы нигезендә су белән тәэмин итү һәм (яисә) су агызу өлкәсендәге чаралар буенча тоташтырыла торган йөкләнешнең бәясе, тәүлегенә мең сум/куб.м.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге